ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

10.04.2026г. **Чистай ш.** № 142

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 30.07.2021 № 431 карарына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 27.06.2019 № 334 карарының үз көчен югалтуын тану хакында

Муниципаль хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 05.02.2024 ел № 124 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 30.07.2021 № 431 карарына (алга таба – 431 номерлы карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең күрсәтелгән карар белән расланган административ регламентын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты».

1. Гомуми нигезләмәләр...

1.5. ...планлаштыру структурасының элементы-зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), яр буе, бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциягә карамаган берләшмәләренең урнашу территорияләре;

- урам-юл челтәренең элементы-урам, проспект, тыкрык, юл, мәйдан, бульвар, тупик, съезд, шоссе, аллея һәм башкалар;

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты ...

2.3.2. Адреслашу объектына яңа адрес бирелгән очракта адреслашу объектының адресын юкка чыгару турындагы карар әлеге адреслашу объектына яңа адрес бирү турындагы карар белән берләштерелә.

2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты:

- кәгазьдә бирелгән гариза теркәлгән көннән алып 10 эш көненнән дә артык түгел;
- электрон документ рәвешендә бирелгән гариза теркәлгән көннән алып 5 эш көненнән дә артык түгел....».

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 27.06.2019 ел 334 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э. Р. Хәсәнов